**Сибгаева Ф.Р. (КДУ)**

## Дәрдмәнд иҗатында “Мәхәббәт” концепты

Татар язма әдәбияты, милли тел формалашуда XX гасыр башы үзенчәлекле урын алып тора. Хронологик яктан үз эченә кыска вакыт аралыгын алса да, Яңарыш хәрәкәтенең иң югары ноктасына менгән дәвер. Шагыйрьләр үзләренең милли чынбарлыкка, иҗтимагый-икътисади яңарышка мөнәсәбәтен, тарихи барыш, милләтнең үткәне, бүгенге хәле, киләчәге турындагы уйлануларын реаль детальләр, сурәтләр аша тасвирлау белән бергә символик, аллегорик образлар ярдәмендә чагылдыра башлыйлар: диңгез, давыл, җил, таң, кояш, йокы һ.б. Бер яктан, шәхес иреге, фикер хөрлеге, милли азатлык, чынбарлыкка кискен мөнәсәбәт кебек мотивларның көчәюе, икенче яктан, лирик геройның хисси-эмоциональ дөньясын сурәтләүнең өстенлек итә башлавы, яшәешнең фәлсәфи, мәңгелек темаларга мөрәҗәгать итүе урын ала. Романтик юнәлеш вәкиле булган Дәрдмәнд иҗатында да бу үзенчәлекләр чагылыш таба.

XXI гасыр башында тел белемендә яңадан-яңа юнәлешләр барлыкка килде. Соңгы елларда тел һәм мәдәниятнең бәйлелеген өйрәнү актуальләшеп китте. Галимнәрнең бу өлкәдә кызыксынып эшләүләре нәтиҗәсендә, XX гасыр. ахырында тел берәмлекләренең милли-мәдәни семантикасын өйрәнә торган лингвомәдәният фәне дөнья күрде. *Лингвомәдәният* – тел белеменең телдә миллилекне, мәдәниятне чагылдыру мәсьәләләрен өйрәнә торган юнәлеш.

Лингвомәдәният фәне кысаларында барлык телләрнең гомуми һәм үзенчәлекле якларын ачыкларга мөмкин. Бөтен телләргә дә хас гомуми сыйфатлар дигәндә, телнең антропоүзәкчел характерда булуы күз алдында тотыла. Беренчедән, тел – кеше ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен барлыкка килгән күренеш, ягъни ул табигать тарафыннан кешегә хезмәт итү өчен яратылган. Икенчедән, тышкы дөнья, әйләнә-тирәлек күренешләре һәм объектларының телдә төрле категорияләргә бүленүе кешене күз алдында тотып башкарыла [Вежбицкая, 1997: 21].

Кешенең эчке һәм хис-кичереш дөньясын чагылдыра торган концептларны өйрәнү аеруча кызыклы (*“Җан”, “Ирек”, “Хәтер”, “Сагыш”, “Мәхәббәт”* һ.б.), чөнки алар ярдәмендә теге яки бу халыкның, иҗат әһеленең милли үзенчәлеген билгеләп була. Моннан чыгып, фәнни тикшеренүнең предметы итеп, татар теле концептосферасының бер өлешен тәшкил иткән, лингвомәдәни *“Мәхәббәт”* концептын Дәрдмәнд иҗатында өйрәнүне алдык.

Мәхәббәт – кеше хисләренең иң серлесе. Мәхәббәткә бер үк вакытта иртәнге сафлык та, кичке талчыгу да хас. Ул барлык башка хисләргә дә үтеп керә, кеше күңелендә сәер үлчәү барлыкка китерә: бер кеше һәм барлык кешеләр, бер зат һәм бөтен кешелек дөньясы бертигез тарта.

“Ярату – син сөйгән һәм сине сөйгән затны мөмкин кадәр якын иткәндә, барлык сизү органнары белән тойганда ләззәтләнү ул”. “Мәхәббәт – хисләрнең тәүгесе”, – дигән аның турында француз язучысы Фонтенель. Һәм ул күп яктан хаклы да: мәхәббәт – әйтерсең лә, барлык хисләр бәйрәме, кавышуга гаять көчле омтылыш, бөтен барлыгың белән яраткан кешеңә мөмкин кадәр якынрак булу ул.

Дәрдмәнд иҗатында *“Мәхәббәт”* концепты исем *(мәхәббәт, сөю, ярату, гыйшык(лык), дәрт, наз)*, сыйфат *(мәхәббәтле, гашыйк, дәртле, назлы)*, фигыль *(сөю, ярату, иркәләү, ошату, назлау, якын итү)* кебек репрезентантлар ярдәмендә чагылыш таба.

Поэтик текстларда исем сүз төркеменнән булган репрезентантлар еш кына метафоралар барлыкка китереп сурәт тудыруга сәләтле.

Метафора семантикада күп планлылык нигезендә тора торган үзенчәлекле төш элемент вазифасын үти һәм тел белемендә концептларны өйрәнүдә әһәмиятле роль башкара. Лингвистика өлкәсендә эшләүче кайбер галимнәр метафорага дөньяны модельләштерү хас һәм ул когнитив корал буларак кулланыла ала, диләр (Дж. Лакофф, М. Джонсон, М.В. Никитин һ. б.), чөнки аңда ассоциатив күзаллау семантик күплекнең бер формасы буларак карала [Лакофф, Джонсон, 1990: 382]. Танып белү өлкәсендә

метафора яңа төшенчәләр һәм күзаллаулар тудырырга сәләтле түгел, ә аларны караңгылыктан якты дөньяга чыгаручы кендек әбисе функциясен генә башкара [Никитин, 2002: 257], ягъни ул, нинди дә булса төшенчәне торгызырга теләп, кеше аңында сакланган модельне репрезентацияли. Билгеле, метафора концепт була алмый, ул бары тик концептларның үзара йогынтысында репликация, репрезентация формалары гына була ала.

Метафора ул – хисси образда авыр кабул ителә торган абстракцияне аңлауның бердәнбер төре. Метафора һәрбер “абстракт предметлар”ның нигезендә ята: матурлык, бәхет, ирек, сагыш, мәхәббәт – болар барысы да семантик яктан субстантивлашкан “абстракт предметлар”.

Дәрдмәнд шигъриятендә хисси образларны субъектка бәйле рәвештә өйрәнгән вакытта, *“Мәхәббәт”* лингвомәдәни концепты ия булган күчерелмә мәгънәләрнең түбәндәге төп семантик төрләре булуы ачыкланды:

1) биоморф метафора (антропо-, зооморф, ботаник):

– мәхәббәт ул – гөл (үсемлек):

*Бер тамаша кыйл, күңел, кем, җиргә беткән гөл түгел,*

*Чын мәхәббәт гөлләредер кунды тәнкәй агына!..* (“Хәят”)

– мәхәббәт ул – нindидер искә ия булган зат:

*Нә җирдә гыйшык вә сәүдаэләр исе бар,*

*Аның шул җирдә кабре... Шунда ул яр!..* (Хикәяи гыйшык”)

2) реиморф (предметлы) метафора:

– мәхәббәт ул – бакча:

*Очмак өчендер мәхәббәт багына (бакчасына) ул гандәлиб,*

*Чәч тарап, көзге карап, салкем канаткай кагына.* (“Хәят”)

– мәхәббәт ул – ут:

*Янды Мәҗнүн, янды Фәрһәд,* -

*Бер янып ат алдылар.*

*Мин, гариб, мең кат янып та,*

*Яндыга саналмадым. (“Бүзләрем мана алмадым”)*

– мәхәббәт ул – буш пространствоны тутыра торган сыеклык:

*Әмма шул көннәрне, кем, булган иде,*

*Гыйшык илә моңлы күңел тулган иде... (“Кичә күр, иркәм...”)*

Дәрдмәнд иҗатында *“Мәхәббәт”* түбәндәге эчке һәм тышкы билгеләргә ия:

а) **тышкы билгеләр:**

– **шәхесләштерү**: *мәхәббәт исе;*

– **предмет:** *мәхәббәт бакчасы;*

**– «яну урыны»**: *мәхәббәт утында яну;*

**– сыеклык:** *күңел гыйшык белән тулу;*

б) **эчке билгеләр:**

– **тереклек**: *мәхәббәт гөле.*

Шулай итеп, анализланган материал нигезендә, без лингвомәдәни *“Мәхәббәт”* концептының Дәрдмәнд иҗатында төрлечә репрезентацияләнә, тышкы һәм эчке билгеләргә ия була ала торган эмоциональ концепт икәнлегенә инандык. Бу аның тирән тарихи-мәдәни эчтәлеккә ия булуы, билгеле бер лексик берәмлекләр семантикасында әһәмиятле урын алып торуы турында сөйли торган нигезле дәлил.

**Әдәбият**

1. Вежбицкая А. Язык. Культура. Познание / А. Вежбицкая. – М.: Языки славянской культуры, 1997. – 792 с.

2. Лакофф Дж. Метафоры, которыми мы живем / Дж. Лакофф, М. Джонсон // Теория метафоры. – М., 1990. – С. 387-416.

3. Никитин М.В. Основы лингвистической теории значения / М.В. Никитин. – Москва: Высшая школа, 2002. – 342 с.